ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2022 Кыр Шонталы авылы № 8

**Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталы авыл җирлегенең социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын расларга (Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.12.2021 ел, № 21 «Социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннарын алмашу буенча документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://alekseevskiy.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталы авыл җирлеге Советы бинасындагы махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Кыр Шонталы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты житәкчесенен**
**вазыйфаларын башкаручы** **Г.Н.Киямова**